КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 10 июнь г.Казань № 415

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт архивлары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2019 ел, 9 август, 663 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт архивлары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2019 ел, 9 август, 663 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 26 июль, 645 нче; 2022 ел, 22 сентябрь, 1027 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт архивлары хезмәткәрләре вазифалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт архивларының эшчеләр гомумтармак һөнәрләре һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Бу карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин